«Кыйссаи Сәкам»*

7. Сәкамнең Хуранга кайтырга чыгуы, юл мажаралары

142. Ул Сәкам Галинең сүзин ишетүбән,
Бетерде Хуран сарый йул тотубән.
143. Күрәрү кем берәкү йулда катыйг барур,
Ачбан, арыйбан, сусайубан барур.
144. Йитеб килди, Сәкам ул ирни күрүб,
Бер сәгать ул ирнең катында торуб.
145. Бу Сәкам әйди: кайу йирлик ирдүң,
Ни эшкә бу йирдә сусабан тордыйң?
146. Ул әйүр кем: белгил, әй, дәлил пәһлеван,
Жиһаншаһ — шаһым торур, йирим — Хуран.
147. Мине дар ул, йәшерб Мәккәгә изди,
Ул Сәкамни монча кичә калдый тийүр.
148. Ишеттем мин — Сәкам мөселман булмыш,
Галидин үзенгә амандар куймыш.
149. Йәнә һәм Сәкамга әймишләр үзин,
Килүрмез тимешләр, ун көндә кизин.
150. Гали берлә килүр ул һәмзә пәһлеван,
Хараблыйк кыйлгайлар безни рәүван.
151. Катыйг эш ишетеб катырак барурмын,
Жиһаншаһ шаһымга чарлаб әйтүрмен.
152. Бу сүзни сүзләди ул ир аңламайын,
Бигакыл кешиләр сагынмаз кизин.
153. Күр эшин, казаның ниләр булгусы,
Тилдин ушал ир тапкыл үлгүсе.
154. Бу Сәкам ул сүзни ишетти ирсә,
Кылыч берлә ордый ул ирне кисә.
155. Үлтүрди бу йирдә ул ирни Сәкам,
Шад булубән барды бигамь.

8. Сәкамнең Хуранга кайтып Жиһаншаһ кызына өйләнүе

156. Хуран эчрә йегет һәм хуҗа,
Күрүшдиләр әйәмен азакыйн хуҗа.
157. Бу Сәкам Делдүлни зөлфокар билә,
Күңлүм шад булубән севенеч кыйла.
158. Жиһаншаһ зөлфокар, Делдүлни күрүб,
Агладый, Сәкамни кочдый кем торуб.
159. Катында ултурдый, әйүр: әй, җуан,
Ихсанәтә килдүң дир дәлилә пәһлеван.

* Ахыры. Кереш мәкаләне һәм башын журналның үткән саннарыннан кара: Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2006. – № 2. – Б. 173-179; 2007. – № 1. – Б. 202-208.

160. Мин айганный килтүрдүң миңа,
Уш имди бирәйен кызыймный сиңа.
161. Бетерүб килтүрдиң бу айгайный эшем,
Бирәйен сиңа нигярин тик кызыйм.
162. Җиһаншаһ илгә байурдый рәүван,
Аш эчкү-йыйгубән кыйлыңлар миһман.
163. Җөһүдләр туйлаш мәҗлес кыйлдыйлар,
Зөлфокар, Делдүлни барча күрдиләр.
164. Йәнә һәм килтүрмеш Мәликнең гөрзүсин,
Җиһаншаһ бирүр тиб Сәкамга кызыйн.
165. Олуг туй кыйлдыйлар олу-кечи,
Калмадый Хуранда иркәк-теши
166. Төп-төгәл йыгдый чирикин камуг,
Калмадый Хуранда йәнә тирсә муг.
167. Зөлфокар, Делдүлгә нәзар кыйлдыйлар,
Туйлаш Сәкамга кызный бирдиләр.

Хуранда Сәкам алып кайткан Гали коралларын тамаша итү

168. Туйла төкәтди җөһүдләр ашыйн,
Күрүб таңладыйлар Мәликнең гөрзүсин.
169. Утыз мең чирикдә бер ир булмадый,
Зөлфокарны кынындыйн чыкара алмадый.
170. Йәнә бер ир чыкмадый Делдүлгә менә,
Катыйга килүбән йөгәнин ора.
171. Мәликнең гөрзүсин таңландый күргән,
Ул гөрзүниң агрый йөз йитмеш батман.
172. Җөһүдләр күрүб булдый хәйран,
Таң-гажәбкә калдыйлар һәрү җуан.

9. Галинең Сәкам артыннан мәлик белән Хуранга төс үзгәртеп барганы

173. Йәнә уш ишетең Галинең эшин,
Хуран таба барубән сәфәр кыйлмыйшыйн.
174. Бу мәлик әйүр: әй, шири Хода
Бул җаным сиңа кыйлайын уш фида.
175. Кайда син барсаң шаһ намдар,
Сиңа мин булайн чакәр сәляхдар.
176. Гали, әй, атлан — мәлик чин бүгүн,
Биргәй носрәт уганым бу көн.
177. Хуран табардан сәфәр кыйлдыйлар,
Икәкү атланыйб йулга кердиләр.
178. Барурлар бу икисе нөкәр йук алайын,
Тигдиләр шәһәргә ун көндә кизин.
179. Күрдиләр — бер йирдә торур потханә,
Шәһәрнең катыйга килдиләр йәнә.
180. Бер кортка аш-үтмәк килтүрмеш торур,
Йәнә һәм потка табынмыш торур.
181. Гали әйди: кортка, йитүрмеш йулыйн,
Мөселман бул имди, монафикъ ләгыйнь.
182. Ул кортга Галинең сүзүн алмадый,
Һәр ничә сүз әйди — кабул кыйлмадый.
183. Мәликнең бу сүзгә ачыгы килеб,
Кылычыйн чыкардый илкендән алыйб.

184. Ул мәлик түшүрди кортка башыйн,
Икәкү ултуруб йидыйлар ашыйн.
185. Гали әйди мәликкә: ишеткәйсен,
Бу йулдан син, бу йулдан мин керәйен.

10. Мәликнең бәлагә тарганы һәм Галинең яңа бер хәйләсе

(Бу урында бер бит җитми, анда Мәлик Галидән аерылгач бер бәлагә тара һәм аның янына килә. — *М. Ә.*)

186. Гали әйди: ни булдый йәнә?
Ни ишкә торубән чаварсыз йәнә?
187. Ул мәлик әйдүр кем, ишеткел Гали,
Килмешләр тотыб мине алгалый.
188. Айырылыб синдин килүрдә үзүм,
Җиһаншаһ кызыйна төшди күзүм.
189. Бер мәлгун ләгыйнь әйтүр анларның ара,
Күңелсез йамандур йөзи кара.
190. Килеб минем башымга ордый,
Такый мине сүгүбән катыймда тордый.
191. Какубән йибәрдүм аны бу заман,
Атындан йикылыб ул бирди җан.
192. Сүзүм бу, ишем ишеткел Гали,
Аның өчүн килмешләр мине алгалый.
193. Гали әйди: ишеткел, йә пәһлеван,
Нә эшкә кылдың моны шаһи җиһан?
194. Әйтмәдүмми сиңа мин зинһар, зинһар,
Кешегә тигүрмәгел, һәргиз әсмар.

11. Мәлик «шаһ» белән Гали «нөкәр»нең Җиһаншаһка кунакка барганы

195. Гали әйди: кил имди, олуг һалә,
Җиһаншаһ катыйна бу ирләр белә.
196. Җиһаншаһ катыйна керсәңез мәгәр,
Син шаһ улуң, мин сиңа улайын чакәр.
197. Икәкү сүзине сүзләштиләр,
Җиһаншаһ катыйна йитеб кердиләр.
198. Җиһаншаһ буларный күрүб курыкты,
Бер алтундыйн тәхет аңа урун куйды.
199. Гали анда мәликкә ишарәт кылдый,
Мәлик тәхет үзрә кичеб ултурдый.
200. Галишир артка сәляхдар булуб,
Торур ирди бакыйб, нөкәр тик булыб.
201. Шаһиншаһ буларны күрүбән әйүр:
Нөкәрүн тәхеткә ултурсун, тийүр.
202. Җаваб әйди сүзгә рәүван,
Сүзүмне ишеткел, әй бу заман.
203. Кайу йирдә бойурсам мин торурга,
Аның ирке йук монда ултурурга.
204. Бик ултурурмын, айә, шәһрийар,
Колымның ултурурга нә ирке бар.
205. Сезнең тик ирәнләр кайда торгай мәгәр,
Сезнең ил нә йирдәдүр биргел хәбәр.
206. Мәлик әйүр, ишет айә шәһрийар,
Гарәб илләрендә безүм тик ирәнләр.

207. Йәнә әйде: атым ирүр Шәһрийар,
Нөкәрүм атый ирүр Ширзаман.
208. Тамаша өчүндүр бу йиргә килдим,
Гарәб иле илүмдүр, әй шаһым.
209. Ишетдүк бу йаналыг гаҗәб хәйер,
Сәкам килтүрмеш дирләр Делдүл, зөлфокар.
210. Аны ишетеб нөкәрүм билә,
Күргәле килмешмен, килтүргил һалә.
211. Җиһаншаһ әйди: Сәкам җуан,
Мөбарыз ирүр, гайәт дәлил пәһлеван.
212. Мәккәгә бу йирдин йалгуз барыйб,
Галине үлтүрүб сәляхайын алыйб.
213. Җиһаншаһ ничүк бу сүзи әйди,
Мәлик көлүб, Галигә йөз әвүрди.
214. Шаһның бер инак вәзири бар ирди,
Барубән Җиһаншаһы катына керди.
215. Әйтүр кем: шаһ, бу икәкү кеби,
Күрмәдүм һич булар тик адәми.
216. Җиһаншаһ әйтүр: әй, вәзирүм сиңа,
Сүзүм бар йакыйн кил, колак тот бәңа.
217. Имди бәнем куркынычым колдыйн торур,
Бикендән анчә курыкмазмын тийүр.
218. Нагяһ йөзүн баксам һәр заман,
Тәнемдин җаным чыкар тик булдый җан.
219. Сүзләди бу сүзни вәзир берлә хан,
Куркычындан килтүрди сөфрә нан.

12. Җиһаншаһ сараенда кунаклар белән очрашу

220. Бу сөфрә ичендә килтүрди тәгам,
Бойурйан казый әйди йимәгә һәм
221. Ики илкин озатуб кулны салды,
Сөфрәдәне йарин бүри тиди.
222. Бер батман бер йагы чыкадыйр әйди,
Җиһанның йимәкин таңлар иди.
223. Барча тәгамин йөккә төйди мәликзар,
Галинең катында торур зар.
224. Җиһаншаһ әйтүр айә пәһлеван,
Нөкәриңә ирмәсмү һәр йан.
225. Җиһаншага мәлик әйүр билә гайан:
Нөкәрүм-мәлик, үзүм — ач калдым байан.
226. Тәгамең килтүргел, бар ирсә һалә,
Уш имди йикайман нөкәрүм бийлә.
227. Җиһаншаһ чарлайуб җар әйүр:
Тәгамләр бар ирсә, килтүргил, тийүр.
228. Хәббаз йәнә чук килтүрди аш,
Мәлик әйди нөкәр калдый йәнә ач.
229. Мәлик әйди: ишет, айә, шәһрийар,
Минем нөкәрүм торур ач (вә) зар.
230. Җиһаншаһ әйди, нөкәрүңмү (ашы)
Ичендә камры бардур йиймәйдүр ашый.

13. Җиһаншаһның килгән кунакларына Сәкам алып кайткан коралларны күрсәтүе

231. Йәнә әйди мәлик: әй шаһи җиһан,
Килтүргил Делдүл, зөлфокарны рәүван.
232. Җиһаншаһ бер кач ирни изди,
Зөлфокар берлә Делдүлне китергел тиди.
233. Бардый ул кеши Канбарга айур:
Җиһаншаһ, Делдүл, зөлфокарны килтүр тийүр.
234. Җиһаншаһ катыйна килебдүр миһман,
Икәү көтүрләр дәлил пәһлеван.
235. Бу сүзне ишетеб Канбәр севенди,
Мәгәр Гали килдисә, нә булгай тиди.
236. Делдүлне әйә дими, зөлфокарны алыйб,
Җиһаншаһ катыйна керди ул килеб.
237. Бу сәгать Канбәр Галине күрди,
Башыны какдый килубән тордый.
238. Гали ул дәм Канбарга ишарәт кыйлдый,
Гали бу дәм Делдүлне чыкаргыйл тиди.
239. Ул дәм чыкардый дүнди йөзүн,
Канбар аңладый Галинең ишарәт сүзүн.
240. Сайрар ирди Делдүл Галине күрүб,
Акрур ирди каты сийасил оруб.
241. Йәнә бу сәгать бу Сәкам җуан,
Алыйб килди гөрзине ул пәһлеван.
242. Җиһаншаһ әйтүр кем: әй, Сәкам сиңа,
Сүзүм бар әйтәйем, йакыйн кил бәңа.
243. Җиһаншаһ әйүр: әй, Сәкам җуан,
Мәккәгә йалгуз барган син пәһлеван.
244. Бу мәлик тәхет үзрә ултуруб торур,
Килубән нөкәри табугыйн кыйлур...
245. Бу Сәкам әйүр кем: айә, шәһрийар,
Булар тик һәйбәтлү җиһанда кем бар?
246. Бу сүзне сүзләшди Сәкам берлә хан,
Такый әйди мәлик, — әй шаһи җиһан.
247а. Мөбарыйз бик бар ирсә, килсүн тийүр,
Зөлфокарны кынындыйн чыкарсун тийүр.
247б. Җиһаншаһ әйди кем: ишеткел Канбар,
Алыйб кил миңа кем, син зөлфокар.
248. Бу Канбар зөлфокарный аңа бирди,
Ул мәлгунь бакубән аны алдый.
249. Бер кывәт кыйлубән ул мәлгунь күчүн,
Зөлфокарный кынындыйн чыкармак өчүн.
250. Ничә тартдый ирсә һәргиз булмадый,
Зөлфокарый кынындыйн чыкара алмадый.
251. Мәлик ул сәгать Галигә бакдый,
Күлкүсү килүбән күзине какдый.
252. Мәлик әйди: белең, айә, шәһрийар,
Биргүл, чыкарсун аны ушпу нөкәр.
253. Җиһаншаһ әйүр: кем синең бу чакәр,
Чыкарса чыкарур аный такы бу мәгәр.

14. Җиһаншаһ кешеләренең Сәкам алып килгән Гали коралларын тота белмәүләре

254. Чыкарса бирәймен телем мал үкүш,
Сансыз кол һәм бирүрмен алтун-көмеш.
255. Бу мәлик торубән Галигә әйүр:
Зөлфокареңни кынындыйн чыкаргыйл, тийүр.
256. Зөлфокарни тотты сабындыйн рәүван,
Тартубән чыкардый аны ул заман.
257. Башыйндыйн чәверди зөлфокарни йәнә,
Өч кат кемешди тотубән кынына.
258. Җиһаншаһ бу эшкә булубән хәйран,
Башыйн иргабан әйүр, әйә, пәһлеван.
259. Ихсанәт сабаһ шаһ, шаһи дәлил,
Син бары мәлик дик булмадың хәҗил.
260. Йәнә әйди мәлик: айә, шәһрийар,
Делдүлгә менгәле бер ирни чыкар.
261. Җиһаншаһ ачыйг килүбән әйүр:
Барыйбән Шәмәкне килтүрүң тийүр.
262. Барыйбән Шәмәкне алыйб килдиләр,
Җиһаншаһ катыйга кериб тордыйлар.
263. Бу җөһүд килүбән Җиһаншаһ таба,
Уңында торубан бу ирләр рәүван.
264. Әйүр кем: айә, шаһым менәйен моный,
Бер чаулан кыйлубан күрәйен аный.
265. Әгәр булса Делдүл, арысландыйн чәләк,
Менәйен тәрәнгә, әй шаһым, мәләк.
266. Күрүң ул җөһүднең олуг сүзләгән,
Бу Делдүл башыйга оран йөгән.
267. Айакыйн күтәриб менәрдә ләгыйнь,
Сикерди бу Делдүл, белеңләр йакыйн.
268. Иш кыйлды анда ул Шәмәкгә Делдүл,
Тугман тик булдый бу сәгатьдә ул.
269. Җиһаншаһ бу ишкә булуб кайгулук,
Йыйгылыйб килди барча кечик һәм олук.
270. Йәнә бер җөһүд кубубән әйди рәүван,
Йир үбүбән әйүр кем: әй, шаһи җиһан!
271. Дәстүр бир миңа Делдүлгә менгәле,
Ни булдый рәүван әйләгәй әле.
272. Бер мәлгунь кубубән килди йакыйн,
Ишеткел, ни кыйлдый бу Делдүл хакыйн.
273. Бу җөһүд тотубән менәрдә аный,
Җәһәннәмгә барды җөһүднең җаный.
274. Йәнә бер җөһүд-исерүк әйүр,
Җиһаншаһ катыйга килүбән торур:
275. Дәстүр бирәй, шаһым син имди миңа,
Әгәр арыслан ирсә, менәйен аңа.
276. Җиһаншаһ әйүр кем: ул бу сүзим аңлагыйл,
277. Син исерүк торырсын, сүзим тыңлагыл.
278. Исерүк кешиләр тапугыны ни белүр,
Исергән кешиләр арыслан булур.
279. Җиһаншаһ җөһүдни таба белмәди,
280. Ничә сүз әйтсә, кабул кыйлмадый.

281. Бу җөһүд Делдүлне тотубән әйүр,
Сикерүбән менәйен моны тийүр.
282. Бу Делдүл дә оруб ләгыйньни басыб,
Җөһүд үлди, бардый җиһандыйн чыкыйб.
283. Үлтерди ул йирдә Делдүл аный,
Җәһәннәмгә бардый җөһүднең (һәм) җаный.
284. Килтүрүрләр бу эшне күрүб рәүван
Әйтүрләр: ат ирмәс бу, нә кяһан.
285. Ун ирни үлтүрди анда ул,
Илаһи бихакдин ул Мөхәммәд рәсүл.
286. Ул эшни күрүбән такый ушбу шаһ,
Башы кавый кыйлубән кыйлды әй (аһ).

15. Галинең кораллар белән эш итүен күрсәтүе

287. Бу мәлик Галигә ишарәт кыйлур,
Бу Гали Сәкамга бакыйбан торур.
288. Йәнә әйди мәлик: айә, шәһрийар,
Дәстүр биргил, менсүн минем сәляхдар.
289. Дәстүр бир миңа, — тийер делдүлне менеб,
Пәһлеван нөкәрең сәляхдин кыйлыб.
290. Җиһаншаһ әйүр: кем бу нөкәр?
Әгәр менсә моный, такый бу менәр.
291. Такый монча Делдүлнең уза сиңа,
Телим мал, теләңләр бирәйен аңа.
292. Бу мәлик Галигә ишарәт кыйлубән әйүр,
Делдүл уза, рәүван моны килеб йитүр.
293. Кубубән килди хәйдәр үзи,
Бакыйбан танды бу Делдүл күзи.
294. Бу Дөлдүл таба улдым Галине күрүб,
Бу мәйдан эчендә чауланлар кыйлыб.
295. Йитеб мондый белүң улдым ул шир, гарәб
Бу кяфирләр барый кыйлдыйлар гажәб.
296. Бу чаулан кыйлбан ушал пәһлеван,
Җөһүдләр гакыйлдыйн китди ул заман.
297. Җиһаншаһ әйүр бакыйбан: гажәб ир торур,
Җөһүдләр күрүбән тамаша кыйлур.
298. Бу мәлик әйүр кем: айә, шәһрийар,
Пәһлеваның бар ирсә, орушсын булар.
299. Минем бер сәляхдарыйм үлсә, йук зыйан
Синең бер нөкәрең үлсә, тотма сәмар.
300. Бу Җиһаншаһ бу кизин анда үзинә,
Ачыйг килеб кан койулдый күзинә.
301. Чириккә дийер Җиһаншаһ бакыйбан әйүр:
Кем булгай сезнең дик мөбадин? — тийүр.
302. Бар ирди җөһүдләрнең ир бер җуан,
Хуран эчендә ирди үзи пәһлеван.
303. Кубубән килди шаһның катыйга үзи,
Шаһның уңында торуб әйди сүзи.

16. Мәҗлеснең бозылуы һәм бәхәс кубу

304. Диди: дәстүр биргел шаһи җиһан,
Кем әйтмеш, нә булмый, айә, пәһлеван.

305. Шаһа бирди бу кяфер килеб,
Йәнә алмасдыйн бер кылыч алыйб.
306. Мәйданга чыксун күрәйен аны,
Сәкамның утуңда түкәр каны.
307. Гали берлән керди мәйданга бу җөһүд ара,
Галигә кылыч белмәди йәнә җөһүд ора.
308. Ничә хәмлә кылдый җөһүд булмадый,
Кылычын Галигә ора алмадый.
309. Булмадый кылычын кыныйга салыб,
Билендән әлинә кәмәнди алыйб.
310. Кәмәндине Галигә килтүрүб,
Гали хәмлә кылмаз иди тик торуб.
311. Бу җөһүд хәмлә кылдый алтмыш катла,
Гяһ кинмәди кылычын ташлай тота.
312. Хаҗил булдый булгай кызардый йөзи,
Галигә бакубән тилмерди күзи.
313. Такый анда кизин бу шире хәйдәр,
Делдүлгә мениб, тотыйб зөлфокар.
314. Бер гиз хәмлә кылыб ордый аны,
Җәһәннәмгә шул сәгать бардый җаны.
315. Җиһаншаһ әйди кем: нә кылдуң җуан,
Әй, дигай ... дәлил пәһлеван.
316. Имди кем мәликнең бу чакәр,
Үлтүрди нә тик мөбарыйзлар тийүр.
317. Мин аның үчүн алайун тийүр,
Аны тотубән зинданга салайун тийүр.
318. Бу сүзгә мәликнең ачыгы килиб,
Сәкамнең гөрзүсин кулдан алыйб.
319. Әйди: әй, Сәкам, сүзүм бар сиңа,
Ишеткел, әйтәйүм колак тот бәңа.
320. Атлагыл имди һәла дар заман,
Катлангыл бу йулду хуш пәһлеван.
321. Ирәнләр көне ушпу көндүр,
Безгә биргүчи уганым носрәт торур.

17. Җиһаншаһ белән Сәкамның аралары бозылышы

322. Бу Сәкам әйди: әй, шаһи җиһан,
Фида улсун сиңа уш җаным рәүван.
323. Җиһаншаһ моны ишетеб аңладый,
Шәһәргә керди, капугыйн багладый.
324. Йәнә чарлаб әйди: әй, Сәкам җуан,
Тәхшидү уш кыйлдуң миңа пәһлеван.
325. Галинең башыйн килтүргел тидүм,
Сез мөселман булмышсыз белмәдүм.
326. Син миңа бу көн йахшы кылмышсән,
Кызум биргән тапугыйн үтәмешсән.
327. Хуран ичрә сине ирәнләр ара,
Тотубән кылдургаймын мең парә.
328. Бу сүзгә Сәкамнең үфкәсе килди,
Күңлинә нә шәй килсә, кыйлур ирдүң.
329. Әйде: вакыт йитүшди һалә,
Син оруш кыйл булар билә.

18. Җиһаншаһның Гали белән бергә бер сугышы һәм аның кулыннан һәлакәте

330. Җиһаншаһ буларның сүзүн тыңладый,
Чыкубән мәйданга йакыйн килди.
331. Мәйдан ичрә чыкыб әйди кем: йа, Гали,
Килдүм сиңа кил оруш кыйлгалый.
332. Мин белдүм, ул Сәкам хәйлә кылмышын,
Терекләйү сине куйуб килмешен.
333. Әй, Сәкам, ымсыну син кылдуң миңа,
Кызум биргән тапугыйн үтәдүң миңа.
334. Йәнә әйди: Гали, сүзүм бар сиңа,
Йалгуз чыкубән оруш кыйлсана.
335. Гали әйди: андаг булсун әй ләгыйнь,
Ул сыйфатлыг һада әр-мөрсәлин.
336. Йәнә атымдыр Гали әл-Мортаза,
Догачым ирүр Мөхәммәд Мостафа.
337. Әй, ләгыйнь хәмлә кыйлгыл син борун,
Сезнеке әйү сиңа бу көн.
338. Бер хәмлә кылды ул арыслан Гали,
Җәһәннәм төбинә җөһүдниң җаный.
339. Кылыч берлә аны ордый бер күчүн,
Үтүб йиргә керди кылыч очыйн.
340. Җиһаншаһ үлди, гүренә булдый Хуран,
Хараб булдый җөмлә шәһәр хан вә ман.

19. Галинең Җиһаншаһ яклыларны җиңүе һәм Хуранны мөселман иле итүе

341. Кеминең башыны шамшадга ордый,
Барый канга булануб йиргә төшди.
342. Кеминең башыны кәс-кәс кыйлубдур,
Барусының дамагыйн мәст кыйлубдур.
343. Ки һәр берин эшин кыйлганда хәйдәр,
Ки һәр дәм әйтүр ирди «Аллаһу әкбәр».
344. Мәлик һәм вәзирләри калдый хәйран,
Кызыйб билмәди үлгәнни чындан.
345. Сүйәкин бердәй кыйлыб булдый хәбәрдар,
Кырыйлган исекә төшди, булдый әфкяр.
346. Соруң диди, — кем бу дийү — пәримү?
Күземезни баглан, әйа, җадгирмү?
347. Халайыкный кырыйб тәмам итәдүр,
Барыймызның башымызга тийәдүр.
348. Соралың кем, — бу кемдүр? — безгә әйтсүн,
Илемез белсүн, вә сонгыйга йитсүн.
349. Диде: шаһи йегет, кандин килүбсен?
Баһадирларны кырдуң диди гәрсен.
350. Гали Дөлдүлене чарлаб алдый фиәл-халь,
Килеб тәгъзыйм билән ултурдый фиәл-халь.
351а. Диди хак йулыйда талиб таләб ирүрмен,
Таләб дә барчадин галиб ирүрмен.
351б. Чу талиблыкда мин галиб ирүрмен,
Гали ибне Әбүталиб ирүрмен.
352. Әгәр йөз мең баһадирлар хәраб кыйлса,
Кырармын барчасыйн ки кяфер улса.

353. Гали атлыйг хода арысланыдырмын,
Мөселман бәндәнең җаныдырмын.
354. Ирүр пәйгамбәр Әхмәд мохтар,
Аның иңәсидүр солтан Саттар.
355. Ләкабем илтифаты Аллаһ Галидүр,
Кылычым зөлфокар хәйдәридүр.
356. Ирүр җефтем минем хатын кыйәмәт,
Атый Фатыймадур, дингә рәхәт.
357. Бәгырь парәм Хәсән ул бивафадур,
Хөсәйен дәшт шәһид гәр беләдүр.
358. Бу көн миндин баруңызга җәфадур,
Кылычым барча кяфирни чападур.
359. Кайынатам Мөхәммәд мостафадур,
Минем атым Гали әл-мортазадур.
360. Бу сүздин билдиләр кем, Галидүр,
Ишетелгән ушал ирниң иридүр.
361. Диди ул бер заманның фигале,
Ки армансыз берар ушыб калале.
362. Гали әйди, — хуш, андаг кыйлыңызлар,
Йигылыйб барча биәрман булуңызлар.
363. Гали кайтуб барыйб бер йиргә төшди,
Арасында чынан бер кичә кичди.
364. Монади кыйлдый кяферләргә һай, һай,
Галине үлтүрүбмез дидүңез, — ай, ай.
365. Гали безнең билән худиркә икән,
Нөкәри, ләшкәри йуксәйкә икән.
366. Тийү йөз мең чирекни раст кыйлдый,
Мәлик баһадирларыйн хасс кыйлдый.
367. Гали һәм таң намазыйн кыйлдый,
Тулгасыйн алыйб башыйга куйдый.
368. Госсабәсин чормайубән билигә алуб,
Ходаның йадыйный күңлигә салуб.
369. Мөбарыйзләргә баһир кайда килсүн,
Гали тәнһадур аңа хәрабә кыйлсун.
370. Җөһүдләр Галидин бу һәйбәти күрүб,
Мөселман булдыйлар барчасый килүб.
371. Мөселман булдыйлар хакыйкать күңел,
«Тәңрим бер» тидиләр, йәнә «Мөхәммәд рәсүл».
372. Кач көн булар ичендә торуб,
Сәкамгә Хуран илин белдүрүб.
373. Һәр менүб бардый Мәккәгә сарый,
Мәккә иле чыкдыйлар, күрүште барый.
374. Күрүштиләр буларга йегет-карый,
Шад булдый шәһәр или төгәл барый.
375. Рәсүл кочтый йаранларун,
Аңа фида кылдыйлар анлар җанларун.
376. Тоттым битү «Сәкам кыйсса»сыйн,
Укыган онутмасун күңел госсасын.
376. Гали ирәнләри җиһанда куптылар,
Хасе йаранлардан булуб үттеләр.
377. Барча җиһанга тормаз, әй үтәр,
Бу Хуран сәгадәтлү ... вә микән.

СҮЗЛЕК:

Агладый — елады.
Амандар — котылу.
Арыйбан — арып.
Ачбан — ачыгып.
Әвүрди — бордый.
Әндишә — уй.
Әсмар — нәтиҗә.
Әфкяр — яраланган.
Баһир — ачык, гүзәл.
Бигамь — гамьсез.
Бикендән — бигеннән.
Бупануб — болганып.
Гайан — ап-ачык.
Галиб — җиңүче, өстен.
Җадгирмү — сихерчеме.
Җар — кычкырып.
Җефтем — хатыным.
Илкендән — сабыннан.
Илкин — кулын.
Иркәк-теши — ир — хатын-кыз.
Ирмәсмү — түгелме.
Ихсанәтә — ярдәмчелеккә.
Йимәгә — ашамага.
Йыгдый — җыйды.
Кавый — көчле.
Капугыйн — капкасын.
Кач көн — ничә көн.
Кәмәнди — билбау.
Кизин — соң.
Кортка — карчык.
Куркычындан — куркуыннан.
Кяһан — күрүче.
Ләкабем — кушаматым.
Ләшкәри — гаскәре.
Мәст — исерек.
Миһман — кунак.
Монади — кычкыручы, чакыручы.
Монафикъ — ике йөзле.
Монча кичә — моның кадәр.
Мөбадин — алмаштырыр.
Мөбарыз — бергә-бер чыгып сугышучы, пәһләван.
Мөбарыйз — ялгыз, бергә-бер чыгучы.
Мөбарыйзләргә — батырларга.
Муг — мәҗүси.
Нан — икмәк.
Нәзар — карау.
Носрәт — ярдәм, җиңү.
Нөкәр — сугышчы, хезмәтче.
Парә — кисәк.
Потханә — мәҗүсиләр гыйбадәтханәсе.
Сәляхайын — намусын.
Сәляхдарыйм — намуслы, төзек ирем.
Севенди — сөенде.
Соруң — сора.
Сусайубан — сусап.
Талиб — шәкерт.
Тапугыйн — хөрмәтин.
Таңладыйлар — таң калдылар.
Тәгам — икмәк.
Тәгъзыйм — хөрмәт.
Тәнһадур — ялгыз.
Тәхет үзрә — тәхеттә.
Тәхшидү уш — шуны туплап.
Тигдиләр — җиттеләр.
Тигүрмәгел — тимә.
Тирсә — христиан.
Туйла төкәтди — туй белән бетерди.
Уганым — Аллам.
Үлгәнни чындан — тередән.
Үфкәсе — үпкәсе.
Фида — корбан.
Хасс — билгеләде.
Хәббаз — пешекче.
Хәйдәр — арыслан.
Хәҗил — оятлы.
Хәмлә — һөҗүм.
Һада әр-мөрсәлин — илче.
Һәйбәтлү — һәйбәт.
Һәргиз — һәрчак.
Чаварсыз — чабарсыз.
Чакәр — белгечең.
Чакәр сәляхдар — турылыклы хезмәтче.
Чирекни — сугышчыны.
Чук — күп.
Шамшадга — Шам, Дамаск кылычына.
Шири Хода — Ходаның арысланы, ягъни Гали.

Өч кулъязма нигезендә тәнкыйди текстны төзүче,
аңлатмалар бирүче археограф,
филология фәннәре докторы
Марсель Әхмәтҗанов

РЕЗЮМЕ

Окончание средневекового поэтического произведения «Сказание о Сакаме». Литературоведам на сегодняшний день известны четыре рукописных списка сказания: Камкинская, Мало-Кайбицкая, Больше-Менгерская и Усримская. Сюжетом для сказания служила история посылки наемного богатыря Сакама убить вождя мусульман богатыря Али и забрать его военные доспехи. За победу над Али царь неверных обещает Сакаму свою дочь.

В поэме намекается на политику московских князей, которые стали проводить коварную идею разрушения независимости татарских государств. Литературоведом М. И. Ахметзяновым на основе трех списков сказания составлен критический текст, объем которых составляет 377 двухстрочных бейтов.